ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«26» февраль 2024 ел** **№ 148**

**Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү бюджет учреждениеләрен Арча муниципаль районының билгеле бер территорияләренә беркетү турында**

Гражданнарның төп белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга конституцион хокукларын тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, муниципаль мәктәпкәчә белем бирү бюджет учреждениеләрен конкрет территорияләргә беркетү максатыннан Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районының конкрет территорияләренә беркетелгән Арча муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыручы муниципаль мәктәпкәчә белем бирү бюджет учреждениеләре (алга таба - муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре) исемлеген расларга.

2. Арча муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесенә, җирле үзидарә органнарына муниципаль

мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә кабул ителергә тиешле балалар турында мәгълүматлар базасын формалаштырырга тәкъдим итәргә.

3. «Арча муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү бюджет учреждениеләрен билгеле бер территорияләргә беркетү турында» Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 03 февралендәге 108 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Башкарма
комитет җитәкчесе Р.М.Гатиятов

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
«26» 02 ел, № 148
карарына кушымта

**Арча муниципаль районының билгеле бер территорияләренә беркетелгән Арча муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәктәпкәчә белем бирү бюджет учреждениеләре исемлеге**

| № | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең исеме | Территория |
|---|---|---|
| 1 | «Арчаның 1 нче балалар бакчасы» | Арча шәһәре |
| 2 | «Арчаның 2 нче балалар бакчасы» | |
| 3 | «Арчаның 3 нче башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе- балалар бакчасы» | |
| 4 | «Арчаның 4 нче балалар бакчасы – баланы үстерү үзәге» | |
| 5 | «Арчаның 5 нче балалар бакчасы» | |
| 6 | «Арчаның 6 нчы «Сандугач» балалар бакчасы» | |
| 7 | Арчаның 7 нче гомуми үстерү төрендәге «Балачак» балалар бакчасы» | |
| 8 | «Арчаның 8 нче балалар бакчасы» | |
| 9 | «Арчаның 9 нчы балалар бакчасы» | |
| 10 | «Арчаның 10 нчы балалар бакчасы» | |
| 11 | «Арчаның 11 нче балалар бакчасы» | |
| 12 | «Апаз балалар бакчасы» | Апаз, Кызыл Игенче, Каратай авыллары |
| 13 | «Ашытбаш балалар бакчасы» | Ашытбаш, Наратлык, Кысна авыллары |
| 14 | «Васильева Божа балалар бакчасы» | Васильева Божа авылы |
| 15 | «Югары Аты балалар бакчасы» | Югары Аты авылы |
| 16 | «Казанбаш балалар бакчасы» | Казанбаш, Көтек авыллары |
| 17 | «Кәче балалар бакчасы» | Кәче, Чулпан, Якты Көн, Кишмәт авыллары |
| 18 | «Күпербаш балалар бакчасы» | Күпербаш, Казиле авыллары |
| 19 | «Кушлавыч балалар бакчасы» | Кушлавыч, Иске Җөлби авыллары |
| 20 | «Мәмсә балалар бакчасы» | Мәмсә, Кысна авыллары |
| 21 | «Мөндеш балалар бакчасы» | Мөндеш, Югары Мәтәскә авыллары |
| 22 | «Мөрәле балалар бакчасы» | Мөрәле, Ташкичү, Сеҗе, Яңа Ключище, Яңа Чүриле авыллары |
| 23 | «Наласа балалар бакчасы» | Наласа, Урта Бирәзә авыллары |
| 24 | «Түбән Аты балалар бакчасы» | Түбән Аты, Урта Аты, Кылачы, Әрнәш авыллары |
| 25 | «Түбән Мәтәскә балалар бакчасы» | Түбән Мәтәскә, Югары Мәтәскә авыллары |
| 26 | «Яңа Кенәр балалар бакчасы» | Яңа Кенәр, Яңа Ашыт, Кысна, Кызыл Яр, Югары Оры, Сөрде авыллары |

| | | |
|---|---|---|
| 27 | «Яңа Кишет балалар бакчасы» | Яңа Кишет, Иске Кишет, Кышкар, Симетбаш авыллары |
| 28 | «Яңа Кырлай балалар бакчасы» | Яңа Кырлай, Яңа Иябаш, Пионер, Иске Юрт, Югары Бирәзә, Күкчә-Бирәзә авыллары |
| 29 | «Носы балалар бакчасы» | Носы, Ишнарат, Сәрдәбаш авыллары |
| 30 | «Курса разъезды балалар бакчасы» | Курса тимер юл разъезды |
| 31 | «Сикертән балалар бакчасы» | Сикертән, Казалар, Гөберчәк, Чөмә-Елга авыллары |
| 32 | «Курса-Почмак балалар бакчасы» | Курса-Почмак, Иске Муй, Иске Масра, Югары Масра авыллары |
| 33 | «Урта Курса балалар бакчасы» | Урта Курса, Түбән Курса, Югары Курса, Сарай-Чокырча, Алан, Корайван авыллары |
| 34 | «Иске Ашыт балалар бакчасы» | Иске Ашыт, Печмәнтау, Иске Кенәр авыллары |
| 35 | «Иске Чүриле балалар бакчасы» | Иске Чүриле, Ашабаш, Чулпан, Ермоловка, Красная Горка, Платоновка, Татар Кәдрәге авыллары, Чүриле тимер юл разъезды, Михайловка авыллары, Арча шәһәре |
| 36 | «Иске Төрнәле балалар бакчасы» | Иске Төрнәле, Алга Көек, Кече Төрнәле, Четыре Двора авыллары |
| 37 | «Ташкичү балалар бакчасы» | Ташкичү, Наратлык, Акчишмә авыллары |
| 38 | «Орнашбаш балалар бакчасы» | Орнашбаш, Субаш Аты авыллары |
| 39 | «Үрнәк балалар бакчасы» | Үрнәк бистәсе, Күлтәс, Тылаңгыр, Урта Пошалым, Бимәр, Югары Пошалым авыллары |
| 40 | «Утар Аты балалар бакчасы» | Утар Аты авылы |
| 41 | «Өчиле балалар бакчасы» | Өчиле авылы |
| 42 | «Хәсәншәех балалар бакчасы» | Хәсәншәех авылы |
| 43 | «Чиканас балалар бакчасы» | Чиканас, Иске Иябаш авыллары |
| 44 | «Шекә балалар бакчасы» | Шекә авылы |
| 45 | «Шушмабаш балалар бакчасы» | Шушмабаш, Илдус авылы, Үгез-Елга авыллары |
| 46 | «Шурабаш балалар бакчасы» | Шурабаш, Яңа Сәрдә, Шура, Байкал авыллары |
| 47 | «Яңасала балалар бакчасы» | Яңасала, Каенсар авыллары |
| 48 | «Штерә балалар бакчасы» | Штерә авылы |
| 49 | «Пөшәңгәр башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе-балалар бакчасы» | Пөшәңгәр, Миржәм, Каргалы авыллары |
| 50 | Түбән Аты төп гомуми белем бирү мәктәбе филиалы - «Урта Сәрдә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе- балалар бакчасы» | Урта Сәрдә авылы |